ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01. 10. 2018 г.Мензелинск № 1116

## ТР Минзәлә муниципаль районы гомумбелем оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында

Балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген саклау, Минзәлә муниципаль районының гомумбелем оешмаларында укучыларны балансланган кайнар туклану нормасының үтәлешен тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.09.2018 елда кабул ителгән “2019 елга айлык акчалата һәм башка түләүләр турында”гы №767 карары нигезендә

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Гомумбелем бирү учреждениеләре җитәкчеләренә:

1.1. Минзәлә муниципаль район укучыларының кайнар ашын һәр уку көненә 7 сум 40 тиен күләмендәге субсидиядән, ата-ана түләвеннән һәм бизнес-план үтәлешеннән торган суммага оештырырга. Өстәмә дәресләргә йөрүче баллар өчен полдник оештырырга. Шимбә көннәрендә мәктәп ашханәләрендә буфет оештырырга.

1.2. Составы учреждение директоры тарафыннан раслана торган, укучыларга социаль ярдәм чаралары бирү буенча комиссия булдырырга. Комиссия составына туклануны оештыру өчен җаваплы социаль педагогны, ата-аналар комитеты вәкилен кертергә. Комиссия әгъзаларының гомуми саны кимендә биш кеше булырга тиеш.

1.3. 18 яшькә кадәрле 4 һәм аннан да күбрәк балалар тәрбияләнгән гаиләләрдән һәм азкеремле гаиләләрдән булган укучылар өчен бушлай кайнар иртәнге аш һәм көндезге аш оештырырга.

1.4. Өйдә белем алучы укучылар өчен айдагы уку көннәре исәбеннән 20 нче числодан да соңармыйча айга бер тапкыр бер балага көненә 7 сум 40 тиеннән ким булмаган суммага азык-төлек җыелмасы бирергә.

2. Туклану оештыруны контрольгә алырга.
3. Минзәлә муниципаль Башкарма комитеты «Мәгариф бүлеге” МКУга азкеремле һәм 4 һәм аннан күбрәк балалары булган күпбалалы гаиләләрдән булган балаларга бушлай туклану оештыру өчен акча эзләргә.
4. Муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе директорына Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Психолого-педагогик тернәкләндерү һәм коррекция үзәге”нең психолого-педагогик һәм медицина-социаль ярдәменә мохтаҗ балалар өчен уку процессы чорына көн саен 1 кешегә 163 сум 02 тиен суммасына интернатта тәрбияләнүчеләргә җирле бюджет хисабыннан биш тапкыр туклану оештырырга.
5. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Минзәлә шәһәренең “Гимназия” муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе директорына уку процессы чорына көн саен 1 кешегә 163 сум 02 тиен суммасына интернатта тәрбияләнүчеләргә җирле бюджет хисабыннан биш тапкыр туклану оештырырга. Мәктәп ашханәсендә туклануны катгый рәвештә 12 көнлек меню буенча башкарырга.
6. Куркынычсыз, рациональ, баллансланган туклану тәкъдим итүне объектив контрольгә алу, әзер ризыкларның сыйфатын, әзерләү технологиясенең үтәлешен, санитар-гигиеник таләпләрнең үтәлешен, балаларның туклануын контрольгә алуны башкару максатларында, бракераж комиссиясе төзергә.
7. Мәктәп ашханәсе эшен контрольгә алу, меню буенча укучылар өчен әзерләнгән ризыкның санын һәм сыйфатын тикшерү, оптималь шартлар тудыруга һәм мәктәп туклануын оештыру формаларын булдыруга ярдәм итү максатларында, мәктәптә туклану оештыруның сыйфатына контроль буенча комиссия төзергә.
8. Минзәлә муниципаль районының гомумбелем учреждениеләрендә туклануны оештыруга контроль буенча район комиссиясен төзергә. ТР Минзәлә муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикееваны комиссия җитәкчесе итеп билгеләргә.
9. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Минзәлә муниципаль район
Башкарма комитеты Җитәкчесе
вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МЕНЗЕЛИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ * ОГРН 1061682000380 р 06 92/09 Исполнительный комитет Мензелинского муниципального района ИНН 1628006341